| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КИЛЬДЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ КИЛДИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|
| ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР |
| 14.12.2017 | 23 |

с. Кильдеево

Депутатларның сайлаучылар белән очрашуларын үткәрү өчен бирелә торган урыннар исемлеген һәм аларны бирү тәртибен билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, 2004 елның 19 июнендәге «Җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар турында» 54-ФЗ номерлы, Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлеге Уставы нигезендә,

КАРАР БИРӘ:

1. Россия Федерациясе Дәүләт Думасы депутатларының, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының, Югары Ослан муниципаль районы Советы депутатларының, Килди авыл җирлеге Советы депутатларының сайлаучылар белән очрашуларын уздыру өчен махсус бирелгән урыннарны әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә билгеләргә.

2. Россия Федерациясе Дәүләт Думасы депутатларының, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының, Югары Ослан муниципаль районы Советы депутатларының, Килди авыл җирлеге советы депутатларының сайлаучылар белән очрашуларын уздыру өчен бирелә торган биналарның исемлеген әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә билгеләргә.

3. Әлеге карарның 2 пунктында күрсәтелгән биналарны бирү тәртибен әлеге карарга 3 нче кушымта нигезендә билгеләргә.

4. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштырырга.

Югары Ослан муниципаль районы
Килди авыл җирлеге башлыгы Бурдин В.М.

Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлеге башкарма комитеты башлыгының
2017 елның 14 декабрендәге
23 номерлы карарына
1 нче кушымта

Россия Федерациясе Дәүләт Думасы депутатларының, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының, Югары Ослан муниципаль районы Советы депутатларының, Килди авыл җирлеге Советы депутатларының сайлаучылар белән очрашуларын уздыру өчен махсус бүлеп бирелгән урыннар

1. Килди авылы, Үзәк урам, 15 йорт - шәхси эшмәкәр Камальтдинов кибете янындагы территория.

2. Уланово авылы, Заозерная урамы, 17 йорт - Васин ИП кибете янындагы территория.

3. Харино авылы, Нагорная урамы - Бөек Ватан сугышында һәлак булган сугышчыларга һәйкәл янындагы территория.

Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлеге башкарма комитеты башлыгының
2017 елның 14 декабрендәге
23 номерлы карарына
2 нче кушымта

Россия Федерациясе Дәүләт Думасы депутатларының, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының, Югары Ослан муниципаль районы Советы депутатларының, Килди авыл җирлеге Советы депутатларының сайлаучылар белән очрашуларын үткәрү өчен бирелә торган бүлмәләр исемлеге

| № т/б | Адресы | Балансчы |
|---|---|---|
| 1 | Килди авылы, Үзәк урам, 1 йорт «Килди НОШ» МБОУ | МКУ " Мәгариф бүлеге" |

Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлеге башкарма комитеты башлыгының
2017 елның 14 декабрендәге
23 номерлы карарына
3 нче кушымта

Россия Федерациясе Дәүләт Думасы депутатларының, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының, Югары Ослан муниципаль районы Советы депутатларының, Килди авыл җирлеге Советы депутатларының сайлаучылар белән очрашуларын үткәрү өчен бидалар бирү тәртибе

1. Әлеге тәртип «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә сайлаучылар белән очрашулар уздыру өчен урыннар бирү шартларын билгели.

2. Килди авыл җирлегенең башкарма комитеты Россия Федерациясе Дәүләт Думасы депутатларының, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының, Югары Ослан муниципаль районы Советы депутатларының, Килди авыл җирлеге Советы депутатларының сайлаучылар белән очрашуларын уздыру өчен бирелә торган биналарның исемлеген билгели

3. Әлеге тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән бинадар түләүсез нигездә бирелә.

4. Депутатлар бинаны бирү өчен, сайлаучылар белән очрашу уздыру өчен, оешма җитәкчесе, учреждение, балансында бина урнашкан предприятие адресына бина бирү турында гариза җибәрә.

5. Гаризада чараны уздыру датасы, вакыты, дәвамлылыгы, катнашучыларның якынча саны, заявканы бирү датасы, чараны уздыру өчен җаваплы күрсәткечләр, аның контактлы телефоны күрсәтелә.

6. Бүлмәне бүлеп бирү турында гариза гариза гариза биргән көннән алып өч көн эчендә оешма, учреждение, предприятие җитәкчесе тарафыннан карала.

7. Бинадар эш көннәрендә бу эш процессына комачауламау шарты белән бирелә. Ял (бәйрәм) көннәрендә бина оешма, учреждение, предприятиеләр җитәкчеләре белән килештереп бирелә.